Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге Званка авылы
Лесная урамы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

1 ноябрь, 2025 ел № 4

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге Званка авылы Лесная урамы гражданнарының 2025 елның 1 ноябрендәге җыены беркетмәсе нигезендә түбәндәгеләр ачыкланды:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм гражданнар җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 87 (сиксән җиде).
- халык җыенында эшендә катнашкан гражданнарның гомуми саны 45 (кырык биш).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 45 (кырык биш).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез 2026 елда Кощаково авыл җирлеге Званка авылы Лесная урамында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 6000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлны ремонтлау)» **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Кощаково авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Кощаково авыл җирлеге башлыгы З.Н. Саттарова